**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча шәһәре,Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

**Республика Татарстан**
**Муниципальное образование город Арск**
**Арского муниципального района**
**Совет города Арск**
**422000, г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-15-25, 3-16-25**

## Арча шәһәр Советы
## КАРАРЫ

**«05» май 2021 ел** **№ 35**

### Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 7 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында (29.11.2018 №108, 16.10.2019 №131 карарлар редакциясендә)

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 бүлеге, «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставына яраклаштырып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советы карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Арча шәһәр Советының 2015 елның 03 ноябрендәге 7 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» карарына (29.11.2018 №108, 16.10.2019 №131 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 1.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктча өстәргә:

«3.1. Физик затлар мөлкәтенә салым түләүдән түбәндәгеләрне азат итәргә:

3.1.1. 18 яшькә кадәрге дүрт һәм аннан да күбрәк баласы булган гражданнарны;

3.1.2. Әлеге пунктның 3.1.1. пунктчасында күрсәтелгән гражданнарның балаларын.

Салым ташламасы түбәндәге төр салым салу объектларына карата бирелә:

- фатир, фатирның бер өлеше яисә бүлмә;

-торак йорт яисә торак йортның бер өлеше;

-гараж яки мәйданы 30 кв метрдан да артык булмаган машина урыны.

Салым ташламасы, салым ташламаларын куллану өчен нигезләр санына бәйсез рәвештә, салым түләүченең теләге белән гаиләгә туры килә торган һәр салым салу объектына карата бирелә.

Салым ташламасы Арча шәһәре территориясендә даими яшәүче салым түләүчеләргә салым түләүче тарафыннан салым түләүче милкендәге һәм эшмәкәрлек эшчәнлегендә кулланылмый торган салым салу объектына карата булган салым суммасы күләмендә бирелә.

Салым ташламаларына хокукы булган физик затлар салым органына салым ташламалары бирү турында гаризаны үз сайлавы буенча бирә, шулай ук салым түләүченең салым ташламасына хокукын раслый торган документларны тапшырырга хокуклы.

Салым ташламасына хокукны раслаучы документлар түбәндәгеләр:
-әлеге салым буенча салым түләүче дип танылган физик затның шәхесен таныклаучы документ;
- аның исеменә бирелгән күпбалалы гаилә таныклыгы.

Салым ташламасы бирелә торган салым салуның сайланган объектлары турында хәбәрнамә салым түләүче тарафыннан әлеге объектларга карата салым ташламасы кулланыла торган салым чоры булып торган елның 1 ноябренә кадәр салым органына тапшырыла».

2. Әлеге карар Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы сайтында яисә «Арча хәбәрләре» газетасында рәсми басылып чыккан көннән алып бер айдан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә һәм 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны социаль мәсьәләләр буенча даими эшләүче комиссиягә йөкләргә.

"Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе — И.Г. Нуриев